**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Оштырма Юмья авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2023 елның 19 сентябре** **№ 21**

**Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Сәрдәүч торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Сәрдәүч торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы Сәрдәүч авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Оштырма Юмья авыл җирлеге Уставы нигезендә, Оштырма Юмья авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

2023 елның 30 сентябренә 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Сәрдәүч торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы Сәрдәүч авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сәрдәүч авылы, Чишмәле урамы, 20 нче йорт адресындагы торак йорт янында үткәрергә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Сәрдәүч торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы Сәрдәүч авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:

түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар өстәргә:

- Сәрдәүч авылының юлларына вак таш җәю, ремонтлау, төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Оштырма Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев